СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«01» ноябрь, 2024 ел    Алабуга шәһәре    № 386

Алабуга муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Алабуга муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары, аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 246 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет даирәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмен арттыру турында» 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Алабуга муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары, аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 246 номерлы карарында билгеләнгән, 2025 елның 1 гыйнварыннан Алабуга муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешма, аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган айлык вазифаи окладлары күләмнәрен арттырырга һәм түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Алабуга муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары, аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә

хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган вазифаи окладлары күләмнәре, Алабуга муниципаль районында бюджет өлкәсендәге аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретареның Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган вазифаи оклад күләмен кабатлау белән исәпләнә, һәм ул 13 990 сум тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Алабуга муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисад үсеше, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов